# 2024-2026 елларга Яр Чаллы шәһәренең социаль-икътисадый үсеш прогнозына аңлатма язуы

## Аңлатма язуы

2024-2026 елларга социаль-икътисадый үсеш прогнозы гомумроссия икътисадый хәлен үстерү шартлары, Татарстан Республикасының үсеш тенденцияләре һәм шәһәрнең база тармаклары һәм система булдыручы предприятиеләре үсешенең прогнозлау күрсәткечләре нигезендә эшләнгән.

2023 ел нәтиҗәләре буенча **тулаем территориаль продукт (ТТП)** 354,1 млрд. сум тәшкил итәчәк, чагыштырма бәяләрдә 100,8%. Урта сроклы чорда

тулаем территориаль продуктны формалаштыруны икътисадның төп секторлары: сәнәгать, төзелеш, күпләп һәм ваклап сату сәүдәсе тәэмин итәчәк.

2024 елда тулаем территориаль продукт күләме 101,6% физик күләм индексы белән 373,9 млрд. сум тәшкил итәчәк. 2025 елда – 102,1% индексы белән 395,6 млрд. сум, 2026 елда – 102,3% индексы белән 419,8 млрд. сум.

**2023 ел нәтиҗәләре буенча шәһәрнең сәнәгать предприятиеләре** барлыгы 644,3 млрд. сумлык (ИПП 107,1%) үз продукцияләрен җитештереп, төяп җибәрәчәк, үз көчләре белән эшләр, хезмәтләр башкарачак.

2024 елга шәһәр буенча 685,5 млрд. сумлык сәнәгать продукциясе җитештерү планлаштырыла, сәнәгать җитештерүе индексы – 102,5%. 2025 елда шәһәр буенча сәнәгать продукциясе күләме 731,5 млрд. сум тәшкил итәчәк, 2026 елда – 782,8 млрд. сум, сәнәгать җитештерүе индексы 102,8% һәм 103,2% тәшкил итәчәк.

Агымдагы ел ахырына төп капиталга **инвестицияләр күләме** 76,8 млрд. сум планлаштырыла, бу 2022 ел дәрәҗәсенә карата 100,4% тәшкил итә. 2023 ел нәтиҗәләре буенча ТТПга инвестицияләр өлеше 21,7% тәшкил итәчәк.

2024 елда инвестицияләр күләме 83,4 млрд. сум тәшкил итәчәк (узган ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 103,1%), 2025 елда – 90,5 млрд. сум (103,5%) һәм 2026 елда – 98,8 млрд. сум (104,4%).

Агымдагы елда инвестицияләрне финанслауның төп чыганагы – предприятиеләрнең үз средстволары.

2023 ел йомгаклары буенча эре һәм урта предприятиеләр буенча **төзелеш-монтаж эшләре күләме** 22,9 млрд. сум тәшкил итәчәк, бу чагыштырма бәяләрдә узган ел дәрәҗәсенә карата 100,7% тәшкил итә. 2024 елда подряд эшләре күләме 2023 ел дәрәҗәсенә карата 0,7% үсеш белән 24,1 млрд. сум тәшкил итәчәк.

2025 елда төзү-монтаж эшләре 25,4 млрд. сум (101,2%) күләмендә, 2026 елда – 26,8 млрд. сум (101,7%) күләмендә прогнозлана.

2023 ел нәтиҗәләре буенча торакны файдалануга тапшыру 310,0 мең кв.м тәшкил итәчәк, бу 2022 ел дәрәҗәсеннән 6,1% ка югарырак.

2024 елда һәм аннан соңгы прогнозланган елларда торакны файдалануга тапшыру ел саен 300 мең кв.метр дәрәҗәсендә планлаштырыла.

Шәһәр мохитен һәм инфраструктурасын яңартуның Федераль һәм республика программалары кысаларында, 2023 елда 15,8 млрд. сумлык объектлар төзеләчәк һәм капиталь ремонтланачак. Бу максатлар өчен киләсе елга да әлеге саннан ким акча тотылмаячак.

2023 елда **ваклап сатуның товар әйләнеше күләме,** узган елгы дәрәҗәгә карата 104,2% инфляцияне исәпкә алып, 212,6 млрд. сум тәшкил итәчәк. 2024 елда товар әйләнешен чагыштырма бәяләрдә 2,6% ка арттыру планлаштырыла һәм ул 230,0 млрд. сум тәшкил итәчәк.

2025 елда товар әйләнеше 246,1 млрд. сум (102,6%) күләмендә прогнозлана, 2026 елда – 263,6 млрд. сум (102,7%).

**Социаль индикаторлар**

2023 ел нәтиҗәләре буенча шәһәр халкының уртача еллык саны 545,6 мең кеше тәшкил итәчәк. 2024 елга халык саны агымдагы ел дәрәҗәсендә прогнозлана.

Предприятие һәм оешма хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача саны 2023 ел нәтиҗәләре буенча 181,6 мең кеше тәшкил итәчәк, бу узган ел дәрәҗәсеннән 1,3% ка югарырак. Прогноз ясалган елларда күрсәткечнең бераз үсүе планлаштырыла.

Агымдагы елда хезмәткә түләү фонды 118,2 млрд. сум тәшкил итәчәк, бу 2023 ел дәрәҗәсенә карата 110,8%. 2024 елда хезмәткә түләү фонды 6,8%

ка артачак һәм 126,3 млрд. сумны тәшкил итәчәк. Планлаштырылган үсеш нигездә шәһәрнең эре һәм урта предприятиеләре хисабына тәэмин ителәчәк.

2025 елда хезмәткә түләү фонды 135 млрд. сум *(106,9%)* тәшкил итәчәк, 2026 елда – 144,9 млрд. сум *(107,3%)*.

2023 елда уртача айлык хезмәт хакы, узган елгы дәрәҗәдән 9,3% үсеш белән 54 237,7 сум тәшкил итәчәк. 2024 елда хезмәт хакы, 6,6% үсеш белән 57 827,4 сумга җитәр дип планлаштырыла.

2025 елда хезмәт хакының үсеше – 6,7% *(61674,5 сум)*, 2026 елда – 6,2% *(65521,7 сум)* тәшкил итү прогнозлана.

2023 елның ахырына теркәлгән эшсез гражданнар саны 660 кешене тәшкил итәчәк, икътисадый актив халыкның эшсезлек дәрәҗәсе – 0,23%.

Фаразланган 2024-2026 елларда теркәлгән эшсез гражданнар саны 700 кешене тәшкил итәр, икътисадый актив халыкның эшсезлек дәрәҗәсе – 0,24% булыр дип көтелә.